КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1230

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче, дүртенче абзацлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатлар өчен субсидияләр бирү күләме һәм шартларын билгеләү тәртибе гамәлгә кертелә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 17 ноябрь, 1230 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан
гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт
бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы
бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү
тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – Учреждение, субсидияләр) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү механизмын гамәлгә кертә.

2. Субсидияләр Учреждениягә түбәндәге максатлар өчен бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» ярдәмче программасын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын (алга таба дәүләт программалары) тормышка ашыру кысаларында чаралар үткәрү;

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне тоту чараларын гамәлгә ашыру (әгәр аларның чыгымнары дәүләт хезмәте күрсәтүгә (эш башкаруга) норматив чыгымнарның исәп-хисабына кертелмәгән булса);

мөлкәт сатып алу.

3. Субсидияләр Учреждениегә тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

## II. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

4. Субсидия алу өчен Учреждение Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына түбәндәгеләрне кертә:

бюджет акчасын бирү кирәклеге нигезләнгән (субсидияләр суммасының исәп-хисабы нигезләвен кертеп) аңлатма язуын, шул исәптән тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), чаралар үткәрүгә, мөлкәт (күчемсез мөлкәттән тыш) сатып алуга якынча сметаны, шулай ук тәэмин итеп торучыларның (подрядчылар, башкаручыларның) тәкъдимнәрен, статистика мәгълүматын һәм (яисә) башка мәгълүматны;

әгәр субсидия бирү максаты бу Тәртипнең 2 пунктындагы икенче, дүртенче абзацлары нигезендә чаралар үткәрү булса, чаралар программасын;

әгәр субсидия бирү максаты мөлкәт сатып алу булса, сатып алырга планлаштырыла торган мөлкәт турында мәгълүмат;

әгәр субсидия бирү максаты Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне башкару булса, түләүләрне алучы физик затларның саны (бер елга уртача саны) һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүмат;

субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәсе үтәлү турында салым органының белешмә кәгазен;

килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата Учреждениенең субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка норматив хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычы булмавы турында җитәкче һәм баш бухгалтер, башка вәкаләтле зат тарафыннан кул куелган белешмә кәгазен.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Учреждениедән бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән биш эш көне эчендә аларда бирелгән белешмәнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

6. Учреждение килешү төзергә планлаштырыла торган айның 1 нче көненә карата түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау;

Учреждениенең субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычы булмау;

7. Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) субсидияләр

бирү өчен бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларының кирәкле күләмдә булмавы.

8. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Учреждение бу Тәртипнең 4 пунктында каралган документларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына яңадан тапшырырга хокуклы.

9. Дәүләт программаларын тормышка ашыру кысаларында чаралар үткәрү максатларында субсидия күләме тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы закон белән билгеләнә.

Дәүләт программаларын тормышка ашыру кысаларында чаралар үткәрүгә бәйле булмаган субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары белән билгеләнә.

10. Субсидияләр бирү максатларыннан чыгып, аларны бирү нәтиҗәләре:

бу Тәртипнең 2 пунктындагы икенче, дүртенче абзацлары нигезендә чаралар үткәрүгә субсидия бирелгән очракта, үткәрелгән чаралар саны (кимендә бер чара);

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән субсидия исәбеннән кабул ителгән йөкләмәләр күләме (100 процент күләмендә);

мөлкәт сатып алуга субсидия бирелгән очракта, сатып алынган мөлкәт объектлары саны (кимендә бер мөлкәт объекты).

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

11. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзи, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

әгәр субсидия бу Тәртипнең 2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә бирелгән булса, дәүләт программасы һәм ярдәмче программа исеме күрсәтелеп, субсидия бирү максатлары;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планы;

субсидия күләме;

субсидия күчерү сроклары (графигы);

хисаплылык бирү сроклары;

Учреждение тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, субсидия суммасын кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

килешүгә үзгәрешләр кертү (шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына субсидия бирү өчен элегрәк җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта) нигезләре һәм тәртибе;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты карары буенча берьяклы тәртиптә, шул исәптән Учреждениене үзгәртеп оештыруга (кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш) яки бетерүгә, Учреждение бу Тәртиптә һәм (яки) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозуга бәйле рәвештә, килешүне срогыннан алда туктату өчен нигез;

килешүне Учреждение тарафыннан берьяклы тәртиптә өзүне тыю.

Кирәк булганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү яки килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына субсидияне килешүдә каралган срокта тулы күләмдә күчерә.

## III. Хисаплылыкка карата таләпләр

13. Учреждение Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына түбәндәгеләрне тапшыра:

ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 нчы көненнән дә соңга калмыйча, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап;

ел саен, агымдагы финанс елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап һәм хисап финанс елына субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын тормышка ашыру турында хисап. Хисаплар формалары килешүдә билгеләнә.

14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты килешүдә өстәмә хисаплылык бирү формасын һәм срокларын билгеләргә хокуклы.

## IV. Субсидия бирү максатлары, шартлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

15. Хисап финанс елында субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше (алга таба – субсидияләрнең калган өлеше), хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварыннан соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемenә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан агымдагы финанс елында субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешен бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш) кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешен агымдагы финанс елында бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, Учреждение, хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына финанс белән тәэмин итү чыганагы агымдагы финанс елының 1 гыйнварына субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше булган Учреждениенең үтәлмәгән йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуны һәм аларның күләмен раслый торган документларны (документлар күчермәләрен) җибәрә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат Учреждениедән алынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешен

агымдагы финанс елында бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешен агымдагы финанс елында бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм Учреждение арасында мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

16. Агымдагы финанс елында Учреждение тарафыннан элек башкарылган, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган түләүләрне кире кайтарудан керемнәр (алга таба – дебиторлык бурычын кире кайтару акчасы) булганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Учреждениенең финанс белән тәэмин итү чыганагы дебиторлык бурычын кире кайтару акчасы булган, үтәлмәгән йөкләмәләре булу турында мөрәҗәгатенә, шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуны һәм аларның күләмен раслый торган документларга (документлар күчермәләренә) нигезләнеп, аларны Учреждение файдалану турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат Учреждениедән алынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, дебиторлык бурычын кире кайтарудан файдаланылмый калган акчаны агымдагы финанс елында бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итә.

17. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм дәүләт финанс контроле органы Учреждениегә субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Акчаны максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

19. Субсидия, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча Учреждение тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән максатлар һәм шартлар үтәлмәве ачыкланган очракта, Учреждение тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Учреждение тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару сроклары бозылганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән 30 көн эчендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

______________________________